КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 декабрь г.Казань № 1186

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосалары һәм юл буе полосалары турында» 2008 ел, 1 декабрь, 841 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосалары һәм юл буе полосалары турында» 2008 ел, 1 декабрь, 841 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 18 май, 317 нче; 2014 ел, 25 октябрь, 778 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобиль юллары турында һәм Россия Федерациясендә юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 ел, 8 ноябрь, ФЗ-257 нче Федераль закон нигезендә, юл хәрәкәте иминлеген арттыру, Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмиятенә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосаларыннан һәм юл буе полосаларыннан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 пунктның 1 пунктчасында:

икенче, дүртенче – җиденче, тугызынчы – унберенче абзацларда «төбәк» сүзеннән соң «яки муниципальара» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны төшереп калдырырга;

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы территориясеннән үтә торган федераль әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларындагы юл буе полосалары чикләрендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзацта «һәм Татарстан Республикасы территориясеннән үтә торган федераль әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктның 2 пунктчасында «төбәк» сүзеннән соң «яки муниципальара» сүзләрен өстәргә;

3 пунктта «һәм Татарстан Республикасы территориясеннән үтә торган гомуми файдаланудагы федераль әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының юл буе полосасында» сүзләрен төшереп калдырырга, «төбәк» сүзеннән соң «яки муниципальара» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта «төбәк» сүзеннән соң «яки муниципальара» сүзләрен өстәргә;

5 һәм 6 пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятенә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану кагыйдәләрен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин